| | | |
|---|---|---|
| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ЛЕНИНОГОРСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ<br>РАЙОН», МЭР ГОРОДА<br>ЛЕНИНОГОРСКА | | «ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>ШӘҺӘРЕ МЭРЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.06.2020 г.Лениногорск № 71

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы, Лениногорск шәһәре мэрының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проектын карау буенча җәмәгать тыңлаулары уздыру турында» 2020 елның 15 маендагы 63 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проектына карата кисәтүләре белән бәйле рәвештә, КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы муниципаль берәмлеге Башлыгы, Лениногорск шәһәре мэрының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проектын карау буенча ачык тыңлаулар үткәрү турында» 2020 елның 15 маендагы 63 номерлы карарына җәмәгать тыңлауларын үткәрү вакыты өлешендә үзгәрешләр кертергә.

2. Ачык тыңлауларны үткәрү вакытын 2020 елның 17 августына кадәр озайтырга.

3. Җәмәгать тыңлауларында катнашучылар җыелышын 2020 елның 10 июненнән 2020 елның 12 августына 16.00 сәгатьтә Тимәш авылы, Утыз Имәни урамы, 71А йорт, авыл мәдәният йорты адресы буенча күчерергә.

4. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм рәсми публикатор - «Лениногорские вести» газетасында бастырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы Р.М. Сираевка йөкләргә.

Р.Г. Хөсәенов

В.Н. Маркелова
5-28-28